РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 12 мае** **Чистай шәһәре** **№14/6**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында» 2007 елның 15 ноябрендәге 17/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында» 2007 елның 15 ноябрендәге 17/3 номерлы карары белән расланган (Чистай шәһәре Советының 2012 елның 16 маендагы 15/4 номерлы карары редакциясендә) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов